**СОВЕТ ЯМАШУРМИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422735, Республика Татарстан, Высокогорский район, с. Ямашурма, ул. Советская, 5

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЯМАШИРМЭ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
422735, Татарстан Республикасы, Биектау районы, Ямаширмэ авылы, Совет урамы, 5

Тел./факс 8(84365) 777-02, e-mail:Yamash.Vsg@tatar.ru

**РЕШЕНИЕ**
**21 сентябрь 2020 ел**

**КАРАР**
**№ 1**

## Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Ямаширмә авыл җирлеге Советы депутатлары составыннан Муниципаль берәмлек башлыгын сайлау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Биектау муниципаль районы Ямаширмә авыл җирлеге Уставының 35 статьясындагы 1 өлешенең 9 пункты, 44 статьясындагы 2 өлеше нигезендә һәм хисап комиссиясенең 2020 елның 21 " сентябрендәге 2 номерлы беркетмәсе нигезендә, Биектау муниципаль районы Ямаширмә авыл җирлеге Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. «Биектау муниципаль районы Ямаширмә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгын сайлау буенча яшерен тавыш бирү нәтиҗәләрен расларга һәм 1 нче Ямаширмә бермандатлы сайлау округы депутаты, Ямаширмә авыл җирлеге башлыгы һәм Биектау муниципаль районы Ямаширмә авыл җирлеге Советы рәисе итеп Мөхтәрев Фәнил Камил улын сайларга.
2. Биектау муниципаль районы Ямаширмә авыл җирлеге Советы муниципаль берәмлек башлыгы вазыйфасына керешү көне итеп, аны Биектау муниципаль районы Ямаширмә авыл җирлеге Советы депутатлары составыннан сайланган көн дип санарга.
3. «Җирле үзидарә турында " 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 26 статьясындагы 1 өлеше һәм Ямаширмә авыл җирлеге Уставының 43 статьясындагы 5 өлеше нигезендә Мөхтәрев Фәнил Камил улын Биектау муниципаль районы Ямаширмә авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесе итеп билгеләп куерга.
4. Әлеге карарны Биектау муниципаль районының Интернет челтәрендәге рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru веб-адресы буенча һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталының рәсми сайтында: http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

Утырышта рәислек итүче
Ямаширмә вәкиллекле органы
6 нчы номерлы сайлау округы депутаты Р. Ф. Вәлиуллин